Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

4 август 2023 ел № 5

Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге территориясендә кулланылышта булган терекөмешле лампаларны туплау урыннарытурында

«Җитештерү һәм кулану калдыклары белән эш итү, яктырту җайланмаларын, электр лампаларын гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян итерергә мөмкин булган тиешсез урында җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортировкалау, урнаштыру кагыйдәләрен аслау турында»Россия ФедерациясеХөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары нигезендә,Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2023 елның 30 июнендәге 02-08-02/750 номерлы күрсәтмәсен карап

Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, яктырту җайланмаларын, электр лампаларын гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган тиешсез урында җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортировкалау, урнаштыру кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган Кагыйдәнең 4 пункты нигезендә кулланылышта булган терекөмешле лампаларнытуплау урыннарын билгеләргә, шул исәптән, күп фатирлы йортларда туплау урыннарын оештыру өчен биналар булмаганга туплау мөмкин булмаган очракларда, шулай ук кулланучыларга мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат бирергә.

2. Татарстан Республикасы, Әлмәтмуниципаль районы, Бишмунча авыл җирлеге, Бишмунча авылы Совет ур.57а йорт адресы буенча кулланылышта булган терекөмешле лампаларны туплау урыны итеп махсус тартма билгеләргә.

3. Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитетының «Бишмунча авыл җирлеге территориясендә кулланылышта булган терекөмешле лампаларны беренчел җыюны һәм урнаштыруны оештыру турында» 2016 елның 28 октябрендәге 13 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

4. Әлеге карарныТатарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча ав., Совет ур., 57а, Кама-Елга ав., Кама-Елга ур., 26а, Ак-Чишмә ав., Ак-Чишмә ур., 1, Бахчасарай ав., Җиләкле ур. 1 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соңүз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Бишмунча авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.Г.Фазлиев